ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

26.11.2020 ел Баулы шәһәре №229

Баулы муниципаль районы
территориясендә даими рәвештә
пассажирлар йөртүне һәм
багаж ташуны оештыру турында

«Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте элекрт транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законны һәм «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте элекрт транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-РТЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Расларга:

- Баулы муниципаль районы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрын алып бару тәртибен, 1нче кушымта нигезендә;

- Баулы муниципаль районы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларын билгеләү, үзгәртү һәм туктату тәртибен, 2нче кушымта нигезендә;

- Баулы муниципаль районы территориясендә урнашкан, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары буенча башлангыч һәм (яисә) соңгы тукталыш пунктлары буларак файдалану рөхсәт ителә торган тукталыш пунктлары исемлеген, 3нче кушымта нигезендә;

- Баулы муниципаль районы территориясендә даими рәвештә пассажирлар

йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурста катнашучыларның гаризалары критерийларын бәяләү өчен шкала, 4нче кушымта нигезендә.

2. Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2016 елның 21 мартындагы 61 номерлы, 2016 елның 11 мартындагы 335 номерлы, 2018 елның 6 мартындагы 86 номерлы, 2019 елның 18 мартындагы 70 номерлы карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров

Баулы муниципаль районы
башкарма комитетының
2020 елның 26 ноябрендәге
229 номерлы карарына
1нче кушымта

Баулы муниципаль районы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары Реестрын алып бару тәртибе

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары (алга таба - муниципаль маршрутлар) Реестрын алып бару (алга таба - Реестр) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары турында белешмәләрне кертү, Реестрдан муниципаль маршрутлар турында белешмәләр төшереп калдыру кагыйдәләрен билгели.

1.2. Реестр әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә муниципаль маршрутлар мәгълүматының бердәм мәгълүмати базасыннан гыйбарәт.

1.3. Барлык фактта гамәлдә булган яисә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет) тарафыннан бетерелгән муниципаль маршрутлар турында белешмәләр Реестргакертелергә яки үзгәртелергә яисә аннан төшереп калдырылырга тиеш.

2. Реестрга алып бару тәртибе

2.1. Реестр элекртон рәвештә алып барыла һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Баулы муниципаль районы сайтында (индивидуаль эшкуарның яшәү урыны турындагы белешмәләрдән тыш) урнаштырыла.

2.2. Реестрны алып бару Реестргатиешле үзгәрешләр кертү юлы белән гамәлгә ашырыла. Реестрга үзгәрешләр яңа муниципаль маршрутлар кертелү, булган муниципаль маршрутлар үзгәрү яисә гамәлдән чыгаруга бәйле рәвештә кертелә.

2.3. Реестрга түбәндәге белешмәләр кертелә:

муниципаль маршрутның теркәү номеры;

муниципаль маршрутның номеры;

муниципаль маршрут буенча яисә чикләрендә башлангыч тукталыш пункты һәм

әлеге муниципаль маршрут буенча соңгы тукталыш пункты исемнәре рәвешендәге даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты маршруты исеменә, әлеге муниципаль маршрут буенча соңгы тукталыш пункты урнашкан җирлекләр исеменә;

муниципаль маршрут буенча башлангыч тукталышның һәм ахырга тукталышның яисә җирлекләрнең (чикләрендә әлеге муниципаль маршрут буенча башлангыч тукталыш пункты һәм соңгы тукталыш пункты урнашкан) исемнәре рәвешендә даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты атамасы;

муниципаль маршрут буенча арадаш тукталышлар яки җирлек чикләрендәге арадаш тукталыш пунктлары исемнәре;

муниципаль маршрут буенча тукталыш пунктлары арасында транспорт чаралары хәрәкәте күздә тотыла торган урамнарның, автомобиль юлларының исемнәре;

муниципаль маршрутның озынлыгы;

пассажирларны утырту һәм төшерү тәртибе;

даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның төре;

даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутын билгеләү яисә үзгәртү турында карар белән, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрутын билгеләү яисә үзгәртү хакында муниципаль конртактта һәм (яисә) ачык конкурста катнашучы тарафыннан бирелгән ачык конкурста катнашуга гариза белән каралган транспорт чараларына характеристикалар (транспорт чаралары төрләре, транспорт чараларының класслары, транспорт чараларының экологик характеристикалары, транспорт чараларыннан максималь файдалану срогы, пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның сыйфатына йогынты ясый торган транспорт чараларына характеристикалар);

һәр класслы транспорт чараларының даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өчен рөхсәт ителә торган максималь саны;

даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру датасы;

исеме, урнашу урыны (юридик зат өчен), фамилиясе, исеме һәм, әгәр булса, атасының исеме, яшәү урыны (шәхси эшкуар өчен), даими рәвештә пассажирлар йөртү маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы салым түләүченең идентификация номеры.

муниципаль маршрут буенча пассажирлар йөртү өчен кулланыла торган транспорт чараларының төрләре һәм класслары, һәр класслы транспорт чараларының максималь саны;

муниципаль маршрут буенча пассажирлар йөртү өчен файдаланыла торган транспорт чараларының экологик характеристикалары;

даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру датасы;

юридик затның исеме, урнашу урыны, муниципаль маршрут буенча ташуны гамәлгә ашыручы индивидуаль эшкуарның (шул исәптән гади ширкәт килешүе катнашучыларының) фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта).

3. Реестрга кертү (аннан төшереп калдыру) тәртибе

3.1. Билгеләнгән яисә үзгәртелгән муниципаль маршрут турындагы белешмәләр Реестрга башкарма комитетының тиешле карары кабул ителгән көннән алып 5 эш көне эчендә кертелә.

3.2. Гамәлдән чыгарылган муниципаль маршрут турындагы белешмәләр Реестрдан башкарма комитетының тиешле карары кабул ителгән көннән алып 5 эш көне эчендә төшереп калдырыла.

3.3. Реестрны алып бару башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге (алга таба - Бүлек) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3.4. Бүлек Реестрга вакытында һәм дөрес итеп белешмәләр кертү өчен җаваплы.

3.5. Реестрны Баулы муниципаль районы сайтында урнаштыруны башкарма комитетының мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмати куркынычсызлык бүлеге башкара.

3.6. Реестр Баулы муниципаль районы сайтында тиешле үзгәрешләр кертелгән көннән алып бер эш көне эчендә яңартылырга тиеш.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының эшләр
беләнидарә итүчесе Х.С. Мөгыйнов

Баулы муниципаль районы
башкарма комитетының
2020 елның 26 ноябрендәге
229 номерлы карарына
2нче кушымта

Баулы муниципаль районы территориясендә даими рәвештә
пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль
маршрутларын билгеләү, үзгәртү һәм туктату тәртибе

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Баулы муниципаль районы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларын билгеләү, үзгәртү һәм туктату Тәртибе (алга таба - Тәртип) Баулы муниципаль районы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларын билгеләү, үзгәртү һәм туктату механизмын (алга таба - муниципаль маршрут) билгели.

1.2. Муниципаль маршрут Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының (алга таба - Башкарма комитет) карары белән билгеләнә, үзгәРТелә яисә юкка чыгарыла.

1.3. Билгеләнгән яисә үзгәртелгән муниципаль маршрутлар турындагы белешмәләр Баулы муниципаль районы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары Реестрына (алга таба - Реестр) кертелә, индивидуаль эшкуарның яшәү урыны турындагы белешмәләрдән тыш, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Баулы муниципаль районы сайтында урнаштырыла.

1.4. Муниципаль маршрутны билгеләү, үзгәртү яисә бетерү турындагы карар башкарма комитет тарафыннан муниципаль маршрутны билгеләүнең максатчанлыгы турында карар кабул ителгәндә яисә юридик һәм физик затларның, шулай ук индивидуаль эшкуарларның гаризасы буенча мөстәкыйль кабул ителә. Гариза турыдан-

туры башкарма комитетка тапшырыла, заказлы почта аша, гариза бирүчене сайлау буенча элекртон имза белән имзаланган элекртон документ рәвешендә җибәрелә.

1.5. Муниципаль маршрут билгеләү, хезмәт күрсәтү алты айдан артык булмаган маршрутны яңарту яки гамәлдәге муниципаль маршрут юлын үзгәртү алдыннан комиссия хезмәт күрсәтү хәрәкәт куркынычсызлыгы таләпләренә туры килү-килмәүне тикшерә (алга таба - юл шартларын тикшерү).

2. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутын билгеләү

2.1. Муниципаль маршрутны билгеләүнең максатчанлыгы турында карар кабул ителгән көннән алып 30 эш көне эчендә башкарма комитет тарафыннан комиссия төзелә һәм муниципаль маршрутның юл шартларын тикшерү уздырыла. Комиссия составы һәм юл шартларын тикшерүне уздыру датасы башкарма комитет карары белән раслана һәм билгеләнгән Тәртиптә теркәлә.

2.2. Юл шартларын тикшерү нәтиҗәләре буенча муниципаль маршрутны тикшерү акты төзелә, ул комиссиянең барлык әгъзалары тарафыннан имзалана.

2.3. Юл шартлары юл хәрәкәте куркынычсызлыгының билгеләнгән таләпләренә туры килгәндә, актта муниципаль маршрутны билгеләү мөмкинлеге турында язма ясала.

2.4. Актка кул куйган көннән алып, 10 эш көне эчендә башкарма комитет тарафыннан муниципаль маршрут билгеләү яисә муниципаль маршрутны билгеләүдән баш тарту турында карар кабул ителә.

2.5. Муниципаль маршрутны билгеләүдән баш тарту турындагы карар, мөрәҗәгать итүчегә тапшыру турында хәбәрнамә белән, элекртон имза яисә элемтәнең теләсә нинди башка төре рәвешендә, тиешле карар кабул ителгән вакыттан алып 10 эш көненнән артмаган вакытта җибәрелә.

2.6. Карар теркәлгән көннән 5 эш көне эчендә, билгеләнгән муниципаль маршрутка номер бирелә һәм аның турында белешмәләр Реестргакертелә. Муниципаль маршрут Реестргатиешле белешмәләр кертелгән көннән билгеләнгән дип санала.

2.7. Муниципаль маршрутны билгеләү турында башкарма комитет карары дәүләт конртакты төзү өчен ачык конкурс яисә торг процедураларын үткәрүне оештыру өчен нигез булып тора.

2.8. Мөрәҗәгать итүче тәкъдиме буенча муниципаль маршрут билгеләү кирәк

булган очракта, ул башкарма комитетка, әлеге Тәртипнең 1нче кушымтасы нигезендә, муниципаль маршрут билгеләү турында гариза бирелә.

2.9. Гаризага түбәндәгеләрне үз эченә алган аңлатма язуы теркәлә: муниципаль маршрут билгеләү кирәклеген нигезләү; даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты буенча башлангыч тукталыш пунктының һәм ахыргы тукталыш пунктының исемнәре (яисә чикләрендә башлангыч тукталыш пункты һәм әлеге муниципаль маршрут буенча соңгы тукталыш пункты урнашкан җирлекләр исемнәре);

даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муници-паль маршруты буенча арадаш тукталыш пунктларының исеме яисә чикләрендә арадаш тукталыш пунктлары урнашкан җирлекләрнең исеме;

даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты буенча тукталыш пунктлары арасында транспорт чаралары хәрәкәте күздә тотыла торган урамнар, автомобиль юллары атамасы, шул исәптән тукталыш пунктларын, алар арасындагы ераклыкны, шулай ук характерлы ориентирларны (юллар, юл чатлары, тимер юл аша чыгу урыннары, күперләр һ.б.) күрсәтеп, график сурәт;

пассажирлар утырту һәм төшерү тәртибе (билгеләнгән тукталыш пунктларында гына яисә, әгәр бу законнар белән тыелмаса, маршруты буенча юл хәрәкәте кагыйдәләре белән тыелмаган теләсә кайсы урында);

даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты буенча файдалану планлаштырыла торган транспорт чараларының сыйдырышлылыгы, төре, классы, экологик характеристикалары, һәр класслы транспорт чараларының максималь саны;

даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру датасы.

2.10. Тиешле гаризаны һәм беркетелгән белешмәләрне теркәгән көннән 30 эш көне эчендә башкарма комитет мөрәҗәгать итүченең тәкъдимен карый һәм муниципаль маршрутны билгеләүнең максатчанлыгы яисә гаризаны караудан баш тарту турында карар кабул итә.

2.11. Гариза тиешле формада булмаса, кушымтадагы белешмәләр дөрес булмаса яисә әлеге Тәртипнең 2.9 пунктында күрсәтелгән белешмәләрнең барысы да бирелмәсә, муниципаль маршрутны билгеләү турындагы гаризаны каралмый.

2.12. Башкарма комитет хәбәрнамәсе нигезендә муниципаль маршрутка кертелгән тукталыш пунктларының хуҗалары (баланста тотучылар) әлеге муниципаль

маршрут буенча автобуслар хәрәкәте расписаниесен шушы муниципаль маршрут буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны башлап җибәрү көненә кадәрге көннән дә соңга калмыйча шушы тукталыш пунктларында урнаштыралар.

2.13. Муниципаль маршрутны билгеләүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

маршрутның тукталыш пунктлары Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә туры килмәү;

маршрут уза торган автомобиль юлларының һәм аларда урнаштырылган ясалма юл корылмаларының әлеге маршрут буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру өчен файдаланыла торган транспорт чаралары габаритларына яки массасына туры килмәве;

маршрут составына үткәрү сәләте тиешледән артып киткән тукталыш пунктларын кертү турында тәкъдим булганда;

пассажирлар ташу өлкәсендә административ-техник комиссиянең яңа маршрутны билгеләү яисә гамәлдәге маршрутны үзгәртү мөмкинлеге булмау турында бәяләмәсе.

3. Муниципаль маршрутны үзгәртү

3.1. Муниципаль маршрут үзгәртүгә түбәндәгеләр керә:

тукталыш пунктын гамәлдән чыгару яисә күчерү;

яңа тукталыш пунктын билгеләү;

транспорт чаралары (муниципаль маршрут буенча тукталыш пунктлары арасында транспорт чаралары хәрәкәте гамәлгә ашырыла торган урамнар, автомобиль юллары) йөрү юлларын үзгәртү;

муниципаль маршрут буенча пассажирлар йөртү өчен кулланыла торган транспорт чаралары классларын, һәр класслы транспорт чараларының максималь санын үзгәртү;

муниципаль маршрутта пассажирлар утырту һәм төшерү тәртибен үзгәртү (билгеләнгән тукталыш пунктларында яисә юл хәрәкәте кагыйдәләре белән тыелмаган теләсә кайсы урында);

даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның төрен үзгәртү;

Россия Эчке эшләр минисртлыгының Баулы районы буенча юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе бүлекчәсеннән әлеге муниципаль маршрутның пассажирлар ташу куркынычсызлыгын тәэмин итү кагыйдәләрендә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве турында мәгълүмат алу.

3.2. Башкарма комитет муниципаль маршрутны үзгәртүнең максатчанлыгы турында карар кабул иткән көннән алып 15 эш көнендә муниципаль маршрутны үзгәртү

турында карар кабул ителә. Муниципаль маршрутны үзгәртү турындагы белешмәләр Реестрга кертелә.

3.3. Мөрәҗәгать итүченең тәкъдиме буенча муниципаль маршрутны үзгәртү кирәк булган очракта, ул башкарма комитетка әлеге Тәртипнең 2нче кушымтасы нигезендә муниципаль маршрут билгеләү турында гариза бирелә.

3.4. Гаризага түбәндәгеләрне үз эченә алган аңлатма кушыла:

муниципаль маршрутны билгеләү кирәклеген нигезләү;

әлеге Тәртипкә 3нче кушымта нигезендә форма буенча тиешле үзгәрешләр исемлеге.

3.5. Муниципаль маршрутны үзгәртү турында гариза яисә белешмәләр тиешле булмаган формада бирелсә, белешмәләр дөрес булмаса яисә аларның исемлеге тулы булмаса, гариза кабул ителми.

3.6. Муниципаль маршрутны үзгәртүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның куркынычсызлыгын тәэмин итү кагыйдәләрендә билгеләнгән таләпләргә туры килмәүгә китерә торган муниципаль маршрут парамертларын үзгәртү;

әлеге муниципаль маршрут узачак урамнарның, автомобиль юлларының һәм аларда урнаштырылган ясалма юл корылмаларының әлеге муниципаль маршрут буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру өчен кулланылырга тиешле максималь массалы һәм (яисә) транспорт чаралары габаритларына туры килмәве;

әлеге муниципаль маршрут составына кертелгән тукталыш пунктларының үткәрүчәнлек сәләтенең туры килмәве яисә артып китүе;

әлеге муниципаль маршрут территориясендә әлеге муниципаль маршрутның тукталыш пунктлары булган территориядәге кайсы да булса торак пунктта яшәүчеләрнең ихтыяҗы тәэмин ителмәгән килеш, әлеге муниципаль маршрут тукталыш пунктларын төшереп калдыру;

муниципаль маршрутның тукталыш пунктлары урнашкан территориядә нинди дә булса торак пунктта яшәүчеләрнең ихтыяҗы тәэмин ителмәгән килеш, әлеге муниципаль маршрутта даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өчен файдаланыла торган транспорт чараларының санын һәм (яисә) сыйдырышлылыгын киметү.

3.7. Муниципаль маршрут юлының үзгәрүе сәбәпле, муниципаль маршрутны

үзгәртүнең максатка ярашлы булуы турында карар кабул иткәндә, әлеге муниципаль маршрутка кертелгән тукталыш пунктлары хуҗалары муниципаль маршрутның үзгәрүе турында мәгълүматны әлеге муниципаль маршрутны үзгәртү карары турында башкарма комитеттан хәбәр алынган көннән алып өч көннән дә соңга калмыйча урнаштыралар.

4. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутын бетерү

4.1. вәкаләтле орган түбәндәге очракларда муниципаль маршрутны юкка чыгара:

әлеге маршрут буенча халыкка ихтыяҗ булмау (даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында квартал саен хисаплар нигезендә ачыкланган);

ике һәм аннан да күбрәк муниципаль маршрутларны берләштерү;

«Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте элекрт транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 220-ФЗ номерлы Федераль законның 24 статьясындагы 7 өлешендә күрсәтелгән нигезләр буенча ачык конкурсны узмаган дип тану һәм кабат ачык конкурс уздырмау турында карар кабул итү;

даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру нияте булган яисә даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы гади ширкәт . катнашучы юридик затлардан, индивидуаль эшкуарлардан 6 ай дәвамында әлеге маршрут буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык алу хокукына яисә җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләрне башкаруга дәүләт конртакты төзүгә гариза кермәсә;

Россия Эчке эшләр минисртлыгының Баулы районы буенча юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе бүлекчәсеннән әлеге муниципаль маршрутның пассажирлар ташу куркынычсызлыгын тәэмин итү кагыйдәләрендә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве турында мәгълүмат керү;

башкарма комитетка әлеге муниципаль маршрутка кертелгән урам һәм автомобиль юллары хуҗаларыннан әлеге урамнарның, автомобиль юлларының һәм аларда урнашкан ясалма юл корылмаларының техник торышы әлеге муниципаль маршрут буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру өчен файдаланыла торган максималь тулы массага һәм (яисә) транспорт чаралары габаритларына туры килмәве турында мәгълүмат керү;

әлеге муниципаль маршрутка кертелгән урам һәм автомобиль юллары

хуҗаларыннан, әлеге муниципаль маршрутка кертелгән тукталыш пунктлары урнашкан территориядәге автовокзал хуҗасыннан, әлеге муниципаль маршрутның тукталыш пунктларының үткәрү мөмкинлеге артып китүе турында мәгълүмат керү;

гариза бирүчеләрдән гаризалар килү.

4.2. Мөрәҗәгать итүчеләрнең муниципаль маршрутны юкка чыгару буенча тәкъдимнәре әлеге Тәртипнең 4нче кушымтасы нигезендә муниципаль маршрутны юкка чыгару турында гариза белән рәсмиләштерелә.

4.3. Муниципаль маршрутны юкка чыгару турындагы гаризага муниципаль маршрутны юкка чыгаруны нигезләп аңлатма язуы куела.

4.4. Муниципаль маршрутны юкка чыгару турындагы гариза түбәндәге очракларда каралмый:

Гаризаны тиешле булмаган формада бирү;

муниципаль маршрутны юкка чыгару турында нигезләмә бирмәү;

муниципаль маршрутның тукталыш пунктлары урнашкан территориядәге торак пунктта яшәүчеләрнең ихтыяҗы тәэмин ителмәгән килеш, муниципаль маршрутны юкка чыгару турында тәкъдимнәр бирү.

4.5. Мөрәҗәгать итүче гаризасы буенча муниципаль маршрутны гамәлдән чыгаруның максатка ярашлы булуы турында карар кабул ителгән көннән алып 15 эш көнендә муниципаль маршрутны гамәлдән чыгару турында карар кабул ителә. Гамәлдән чыгарылган муниципаль маршрут турындагы белешмәләр Реестрдан алына.

4.6. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты Баулы муниципаль районы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары Реестрының 2.3 пунктының 1-10 бүлекләрендә каралган көннән билгеләнгән дип санала, 2.3 пунктының 3-10 пунктларында каралган көннән үзгәрешләр кертелгән дип санала.

Әгәр Муниципаль маршрут буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык бирелгән юридик зат, индивидуаль эшкуар яисә гади ширкәт шартнамәсе вәкаләтле катнашучысы белән кимрәк срок килештерелмәгән булса, мондый таныклыкның гамәлдә булу срогы дәвамында аны үзгәртү йә аны билгеләгән Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы яисә җирле үзидарәнең вәкаләтле органы инициативасы буенча тиешле маршрутны гамәлдән чыгару турындагы карар мондый таныклыкның гамәлдә булу срогы тәмамланган көнгә кадәр йөз сиксән көннән дә соңга калмыйча кабул ителә һәм мондый таныклыкның гамәлдә булу срогы тәмамланган көннән үз көченә керә».

4.7. Әлеге муниципаль маршрутка кертелгән тукталыш пунктлары хуҗалары

башкарма комитеттан муниципаль маршрутны юкка чыгару карары алганнан соң өч көннән дә соңга калмыйча, шушы тукталыш пунктларында муниципаль маршрутны юкка чыгару турында мәгълүмат урнаштыралар.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының эшләр
белән идарә итүчесе Х.С. Мөгыйнов

Баулы муниципаль районы территориясендә
даими рәвештә пассажирлар йөртүнең
һәм багаж ташуның муниципаль
маршрутларын билгеләү, үзгәртү
һәм туктату тәртибенә
1нче кушымта

Форма

Баулы муниципаль районының
Башкарма комитетына

________________________________________
(юридик, физик затның һәм шәхси эшмәкәрнең исеме)

Муниципаль маршрут билгеләү турында гариза

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясе буенча узучы ___ даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларын билгеләү мөмкинлеген каравыгызны үтенәм.

Кушымта: ____ биттә ____ нөхсәдә.

_______________________ ___________________ ________________________
(вазыйфа) (имза) (җитәкче ФИО)

Баулы муниципаль районы территориясендә
даими рәвештә пассажирлар йөртүнең
һәм багаж ташуның муниципаль
маршрутларын билгеләү, үзгәртү
һәм туктату тәртибенә
2нче кушымта

Форма

Баулы муниципаль районының

Башкарма комитетына

____________________________________
(юридик, физик затның һәм шәхси эшмәкәрнең исеме)

Муниципаль маршрут билгеләү турында гариза

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясе буенча узучы ________________________________________________________________ даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларын үзгәртү мөмкинлеген каравыгызны үтенәм.

Кушымта: ____ биттә ____ нөхсәдә.

____________________ _______________ _____________________
(вазыйфа) (имза) (җитәкче ФИО)

М.П

Баулы муниципаль районы территориясендә
даими рәвештә пассажирлар йөртүнең
һәм багаж ташуның муниципаль
маршрутларын билгеләү, үзгәртү
һәм туктату тәртибенә
3нче кушымта

Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль автобус маршрутына үзгәрешләр кертүнең чагыштырма таблицасы
№_____ «____________________________________________________»

| Муниципаль маршрутның билгеләнгән параметрлары | Муниципаль маршрутның тәкъдим ителә торган үзгәрешләре | Кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, муниципаль маршрут параметрлары |
|---|---|---|

| | | |
|---|---|---|
| | | |

Баулы муниципаль районы территориясендә
даими рәвештә пассажирлар йөртүнең
һәм багаж ташуның муниципаль
маршрутларын билгеләү, үзгәртү
һәм туктату тәртибенә
4нче кушымта

Форма

Баулы муниципаль районының

Башкарма комитетына

______________________________
(юридик, физик затның һәм шәхси эшмәкәрнең исеме)

Муниципаль маршрут билгеләү турында гариза

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясе буенча узучы ___________________________________________________________ даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутын бетерү мөмкинлеген каравыгызны үтенәм.

Кушымта: ____ биттә ____ нөхсәдә.

______________________ (вазыйфа) ________________ (имза) _______________________ (җитәкче ФИО)

М.П.

Баулы муниципаль районы
башкарма комитетының
2020 елның 26 ноябрендәге
229 номерлы карарына
3нче кушымта

Баулы муниципаль районы территориясендә урнашкан, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары буенча башлангыч һәм (яисә) соңгы тукталыш пунктлары буларак файдалану рөхсәт ителә торган тукталыш пунктлары
ИСЕМЛЕГЕ

| № п/п | Муниципаль район исеме | Торакт пункт исеме | Тукталыш пункты | Тукталыш пункты урнашкан урын |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Баулы | Баулы шәһәре | Автовокзал | ТР, 423930, Баулы шәһәре,С.Сәйдәшев ур, 1Б |
| 2. | | Баулы шәһәре | Иволга | ТР, 423930, Баулы шәһәре, Зиновьев ур |
| 3. | | Югары Фоминовка | Югары Фоминовка | ТР, 423922, Югары Фоминовка, Совет ур. |
| 4. | | Шалты | Шалты авылы | ТР, 423944, Шалты, Совет ур. |
| 5. | | Татар Томбарлы авылы | Татар Томбарлы авылы | ТР, 423921, Татар Томбарлы, Ленин ур. |
| 6. | | Васькино-Туйралы авылы | Васькино-Туйралы авылы | ТР, 423935, Васькино-Туйралы, Үзәк ур. |
| 7. | | Ташлы авылы | Ташлы авылы | ТР, 423926, Ташлы ур, Үзәк ур. |
| 8. | | Кырымсарай авылы | Кырымсарай авылы | ТР, 423924, .Кырымсарай, Совет ур. |
| 9. | | Кызылъяр авылы | Кызылъяр | ТР, 423940, Кызыляр, Совет ур. |

Баулы муниципаль районы

Башкарма комитетының эшләр
белән идарә итүчесе

Х.С. Мөгыйнов

Баулы муниципаль районы
башкарма комитетының
2020 елның 26 ноябрендәге
229 номерлы карарына
4нче кушымта

Баулы муниципаль районы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурста катнашучыларның гаризалары критерийларын бәяләү өчен шкала

| № п/п | Критерийлар / параметрлар | Таләпләргә туры килә | Таләпләргә туры килми |
|---|---|---|---|
| 1. | Юридик зат, шәхси эшкуар, ачык конкурс уздыру датасына кадәрге ел дәвамында гади ширкәт шартнамәсендә катнашучылар яисә аларның хезмәткәрләре гаебе белән булган кеше үлеменә яки гражданнарның сәламәтлегенә зыян китергән юл-транспорт һәлакәтләре саны<br>Искәрмә: эш тәҗрибәсе булмаганда әлеге критерий исәпкә алынмый | 10 | 0 |
| 2. | Юридик зат, индивидуаль эшкуар яисә гади ширкәт шартнамәсендә катнашучылар тарафыннан даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру тәҗрибәсе, ул дәүләт контрактларын үтәүне йә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык белән расланган. | Һәр эшләгән ел өчен 1 балл, ләкин 10 артык түгел | 0 |
| 3. | Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның сыйфатына йогынты ясый торган даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру өчен юридик зат, шәхси эшмәкәр яисә гади ширкәт шартнамәсендә катнашучылар тарафыннан тәкъдим ителә торган транспорт чаралары характеристикалары (мөмкинлекләре чикләнгән пассажирлар, балалар өчен җиһазлар булу һәм башка характеристикалар): | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3.1. | Хәрәкәтчән состав чыккан ел:<br>эш өчен хәрәкәтчән составның 100 %ы булу, һәр берәмлекнең чыгару елы ачык конкурс уздыру елына иң күбе 1 ел алдан;<br><br>эш өчен хәрәкәтчән составның 70 %ы булу; һәр берәмлекнең чыгару елы ачык конкурс уздыру елына иң күбе 1 ел алдан;<br><br>эш өчен хәрәкәтчән составның 40 %ы булу; һәр берәмлекнең чыгару елы ачык конкурс уздыру елына иң күбе 1 ел алдан; | 15<br><br>10<br><br>5 | 0<br><br>0<br><br>0 |
| 3.2. | Экологик күрсәткечләр (һәр берәмлеккә исәпләп):<br>ЕВРО-6 двигателе<br>ЕВРО-5 двигателе<br>ЕВРО-4 двигателе | 0,3<br>0,2<br>0,1 | 0<br>0<br>0 |
| 3.3. | Техник структура:<br>һәр берәмлеккә исәпләп, таләп ителә торган Лот буенча эшләү өчен хәрәкәтчән состав булу | 0,2 | 0,1 |
| 3.4. | Аерым категория гражданнар өчен куллану уңайлылыгы:<br>мөмкинлекләре чикләнгән пассажирлар йөртү, балалар коляскалары булган пассажирлар йөртү өчен җиһазландырылган бер һәм аннан да күбрәк хәрәкәтчән состав булу | 2 | 0 |
| 3.5. | Транспорт чараларын йөртүчеләрнең хәрәкәт, хезмәт һәм ял режимнары (тахограф) үтәлешен техник контроль чаралары белән тулыландыру, һәр берәмлек өчен исәпләгәндә.<br>Искәрмә: әлеге критерий 50 км дан артык муниципаль маршрутларда гына исәпкә алына. | 0,2 | 0 |
| 3.6. | Ачык конкурс үткәрү турында хәбәрнамәдә һәм конкурс документларында бәян ителгән күчмә составның хәрәкәтчән составына карата таләпләргә туры килүе:<br>перевозчик милкендә (һәр транспорт чарасы өчен);<br>башка законлы нигездә<br>(һәр транспорт чарасы өчен);<br>ачык конкурс уздыру турында хәбәрнамәдә һәм конкурс документларында бәян ителгән таләпләргә туры килә торган хәрәкәтчән | 15<br><br>10<br><br>0 | 0<br><br>0<br><br>0 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | составны сатып алу буенча йөкләмәләр срогының заявкалы конвертларны ачкан көннән алып унбиш көннән дә артмавын раслаучы документларның булуы. | | |
| 4. | даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклыкның гамәлдә булу срогы дәвамында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру өчен транспорт чараларыннан файдалануның максималь срогы: | | |
| 4.1. | даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклыкның гамәлдә булу срогы чыккан вакытка маршрутта кулланыла торган транспорт чараларын эксплуатацияләү срогы:<br>5 ел (һәр транспорт чарасы өчен);<br>5 елдан 10 елга кадәр (һәр транспорт чарасы өчен);<br>10 елдан 15 елга кадәр (һәр транспорт чарасы өчен). | 1<br>0,8<br>0,6 | 0<br>0<br>0 |

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының эшләр
белән идарә итүчесе

Х.С. Мөгыйнов